КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 декабрь г.Казань № 1127

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы; 2017 ел, 12 май, 350 нче; 2018 ел, 18 май, 375 нче; 2018 ел, 24 июль, 592 нче; 2018 ел, 8 сентябрь, 762 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта:

беренче абзацта «түләү» сүзен «түләүгә» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максатлар һәм бурычлар өстенлекләрен тәэмин итә.»;

3.2 пунктның унөченче абзацында «Яшьләр эшләре һәм спорт» сүзләрен «Спорт» сүзенә алмаштырырга;

4.1.33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.33. Законнар җыентыгын әзерләү һәм яңарту, аны бастырып чыгару эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин